# Каюм Насыйри әсәрләрен дәресләрдә һәм дәрестән тыш чараларда файдалану

***Хуҗина Р.Т., татар теле һәм әдәбияты укытучысы***

“Без – татарлар, телебез татар теле, мөстәкыйль һәм төзек кагыйдәле камил тел ул”, - дип яза күренекле татар мәгърифәтчесе, галим һәм педагог Каюм Насыйри. Әйе, телебез бай һәм камил. Ул гасырлар буе халкыбызның акылын, гореф-гадәтләрен, тарихын үзенә җыеп, хәзерге көннәргә кадәр китереп җиткергән олы бер хәзинә.

Гомере буе татар халкына хезмәт иткән, хезмәтләре белән татар теленең фән теле булуына ышандыра алган олуг галимебез бүген дә безне каршы ала, озата бара. Аң-белемне ана телендә бирүне, укымышлы кеше булу өчен үз телен белүне җаны-тәне белән хуплаган энциклопедик галим үзе җыйган фольклор әсәрләрен “Кырык бакча”(1880), “Фәвакиһелҗөләсә”(1884), “Китап-әт-тәрбия”(1891), балаларга атап әлифбадан соңгы уку китабында һ.б. хезмәтләрендә туплый. Аларда халкыбызның тормыш-көнкүреше, үзара мөнәсәбәтләре, тәрбия тәҗрибәсе туплана. Без, татар гимназиясе укытучылары, аның әсәрләреннән үрнәкләрне үзебезнең дәресләребездә, тәрбия сәгатьләрендә бик теләп файдаланабыз. “Бала белән күләгә”, “Хәйлә һәм тапкырлык”, “Эчәсең килсә, суны үзең алып кер” һ.б. хикәятләре укучыларыбызны кече яшьтән үк әдәп-әхлаклы итеп үстерүгә гаять зур өлеш кертә. Аларга яман һәм яхшыны, явызлыкны һәм тәүфыйклылыкны, нәфесне һәм чик-чаманы чагыштырып төшенергә ярдәм итә. Урта буын укучылары К.Насыйриның “Әбүгалисина”, “Кырык вәзир кыйссасы” дигән гарәп һәм фарсы телләреннән тәрҗемә ителгән әсәрләрен укып гыйбрәт ала. Әлеге әсәрләрдә кешедәге акыл, гыйлем, зирәклек, әдәплелек сыйфатлары мактала, ә комсызлык, хезмәт сөймәү, ялагайлык, наданлык кебек яклар тәнкыйтьләнә. Һәр көн телевизор экраннарыннан агылган тискәре күренешләргә азмы-күпме каршы торырлык көч таба бу әсәрләрдән укытучыларыбыз да, укучыларыбыз да. Һәр тәрбияче-

укытучының, ата-ананың, яшүсмернең өстәл китабы булырга хаклы “Китап-әт-тәрбия” дигән хезмәте турында аерым әйтеп китәсе килә. Бу затлы рухи хәзинәдәге үгет-нәсихәтләрне хәзерге тормыш белән бәйләп аңлату, проблемалы сорауларны хәл итү процессында төшендерү укучыларыбызга күп нәрсәләргә аек күз белән карарга ярдәм итә. Уникаль галимебезнең кайсы гына хезмәтен алып карасак та, аның бөтен көчен милләтебез балаларының белемле, әдәпле итеп үстерүгә сарыф иткәнлеген күрәбез. Без, кызлар гимназиясе мөгаллимнәре, татар халкының киләчәген тәрбиялибез һәм үз эшебездә аерылгысыз ярдәмчебез булган язучыбыз-галимебез К.Насыйри эшен дәвам итәбез.